**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 5 сентябрь № 645

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре булып торган Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2011 ел, 6 июнь, 449 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре булып торган Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2011 ел, 6 июнь, 449 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 1 март, 143 нче, 2013 ел, 24 май, 348 нче, 2014 ел, 31 гыйнвар, 51 нче, 2014 ел, 11 август, 583 нче, 2015 ел, 18 май, 353 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

«9. Татарстан Республикасы Хисап палатасына беркетелгән керемнәр чыганаклары:

1) акчалата түләүләрдән (штрафлардан) һәм зыянны каплауга бүтән суммалардан шәһәр округлары бюджетларына күчерелә торган башка керемнәр;

2) зыянны каплауга акчалата түләүләрдән (штрафлардан) һәм бүтән суммалардан муниципаль районнар бюджетларына күчерелә торган башка керемнәр.»;

II бүлекнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) акчалата түләүләрдән (штрафлардан) һәм зыянны каплауга бүтән суммалардан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына күчерелә торган башка керемнәр.».

2. Әлеге карарның көче 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\645.docx